# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы
Көек-Ерыкса авыл җирлеге составына керүче Көек Ерыкса торак пунктында
2026 елга үзарасалым кертү турында

№ 5

21.10.2025 ел

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 нчы статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ санлы Татарстан Республикасы законының 35нче статьясы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Көек-Ерыкса авыл җирлеге муниципаль берәмлеге» Уставының 23 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Көек-Ерыкса авыл җирлегенең Көек Ерыкса торак пунктында узган гражданнар җыены

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1.Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Көек-Ерыкса авыл җирлеге Көек Ерыкса торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрбихәрәкәтләрдә катнашкан ветераннар, Бөек Ватан сугышында һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашканнарның тол хатыннары, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән, махсус хәрби операциядә катнашучылардан һәм аларның гаиләләреннән кала, 2026 елда 1000 (Бер мең) сум күләмендә үзарасалым кертергә.

2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга тотарга:

- урамнардагы юлларны вак таш белән ремонтлау: Гагарин ур, Молодежная ур,: (сатып алу, вак таш җәю);
- урамнарга яктырту лампалары, яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу, урнаштыру, алмаштыру;
-юлларны тигезләү һәм кардан чистарту;

3.Әлеге карарны Көек-Ерыкса авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Мамадыш муниципаль районы
Көек-Ерыкса авыл җирлеге Башлыгы,
Совет рәисе

Ф.Р.Шәйхетдинов